ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

2025 елның 20 октябре № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 20.10.2025 елның 10.00 сәгатендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында узган гражданнар Җыенының йомгак беркетмәсе төзелде:«Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, контракт буенча хәрби хезмәт узучы Россия Федерациясе Кораллы көчләре хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 800 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Горшково авылы территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (кышкы чорда юлларны кардан чистарту (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, бензотриммер, бензотриммерларга запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (киртәләр кору (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)).»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 105 кеше кертелгән, 81 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен - гражданнар җыенында катнашкан 81 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1.Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында гражданнар җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, контракт буенча хәрби хезмәт узучы Россия Федерациясе Кораллы көчләре хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 800 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Горшково авылы территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

**-** торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (кышкы чорда юлларны кардан чистарту (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, бензотриммер, бензотриммерларга запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (киртәләр кору (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү))», карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуция челтәрендәге «атарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Горшково авылы, Күл арты ур., 35а номерлы йорт янында мәгълүмат стендында, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге башлыгы

С.Ю.Питеркина